МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13 апрель 2016 ел г.Казань № 173-пр

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫНДА ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАНЛЫК ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ БУРЫЧЛАРЫН БАШКАРГАНДА МӘНФӘГАТЬЛӘР КАРШЫЛЫГЫНА КИТЕРГӘН ЯКИ КИТЕРЕРГӘ МӨМКИН БУЛГАН ШӘХСИ МӘНФӘГАТЬЛӘР БАРЛЫККА КИЛҮЕН ХӘБӘР ИТҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘНЕ РАСЛАУ ТУРЫНДА

"Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге N 273-ФЗ Федераль законга, "Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт хезмәте вазифасын биләүче затларның, башка затларның вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүен хәбәр итү тәртибе турында, һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге N 650 Указы, Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазифаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүен хәбәр итү тәртибе турында Татарстан Республикасы Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 18 мартындагы N УП-265 Указы нигезендә боерым:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүен хәбәр итү тәртибе турында тәкъдим ителгән нигезләмәне расларга.

2. Кадрлар бүлеге мөдиренә (Газизов Р.М.) Татарстан Республикасы Җир һәм

мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, шулай ук, хезмәт контракты төзер алдыннан гражданнарны әлеге Боерык белән таныштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр в.б.
С.А.ДЕМИДОВ

Татарстан Республикасы

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
13 апрель 2016 ел N 173-пр
боерыгы белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫНДА ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАНЛЫК ХЕЗМ ӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ БУРЫЧЛАРЫН БАШКАРГАНДА МӘНФӘГАТЬЛӘР КАРШЫЛЫГЫНА КИТЕРГӘН ЯКИ КИТЕРЕРГӘ МӨМКИН БУЛГАН ШӘХСИ МӘНФӘГАТЬЛӘР БАРЛЫККА КИЛҮЕН ХӘБӘР ИТҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүен хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Дәүләт хезмәткәрләренең Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүен хәбәр итәргә, шулай ук, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча чаралар күрергә бурычлы.

Хәбәр әлеге Нигезләмәгә Кушымтада китерелгән язмача формада мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүе турындагы белдерү рәвешендә тутырыла, һәм Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына (алга таба – министр) юллана.

3. Министр өч эш көне эчендә белдерүне Министрлыкның кадрлар бүлегендәге коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы вазыйфаи затына (алга таба – вазыйфаи зат) беренчел карап чыгу өчен юллый.

4. Белдерүне беренчел карап чыгу барышында җаваплы зат белдерү юллаган дәүләт хезмәткәреннән анда бәян ителгән шартлар буенча ачыклаулар сорый ала, дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләти органнарга, җирле үзидарә органнарына һәм башка кызыксынган оешмаларга тиешле тәртиптә запрос юллауны оештыра ала.

5. Белдерүне беренчел карап чыгу нәтиҗәләре буенча җаваплы зат нигезле бәяләмә әзерли.

6. Белдерү, беренчел карап чыгу барышында алынган башка материаллар,

шулай ук, бәяләмә, җаваплы зат белдерүне алганнан соң җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

7. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән запрослар юлланган очракта белдерү, беренчел карап чыгу барышында алынган башка материаллар, шулай ук, бәяләмә, җаваплы зат тарафыннан Комиссия рәисенә белдерү алынганнан соң 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт Комиссия рәисе тарафыннан озайтыла ала, әмма 30 көннән дә артыкка түгел.

8. Белдерү, бәяләмә һәм башка материалларны Комиссия Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында Нигезләмә нигезендә карый.

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
вазыйфаи бурычларын башкарганда
мәнфәгатьләр каршылыгына
китергән яки китерергә мөмкин булган
шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүен хәбәр итү
тәртибе турында нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре министры
А.К. Хамаевка

________________________________
(вазыйфа атамасы)
___________________________________
___________________________________
___________________________________
(Ф.И.ӘИ., адрес, телефон номеры)

Мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүе турындагы

белдерү

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган (кирәгенең астына сызарга) шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүе турында хәбәр итәм.

Шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүенә нигез булган шартлар:_________________

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Шәхси мәнфәгатьләр үтәлешенә тәэсир итә алган яки тәэсир итәргә мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: ____________________________________________________

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим

игелгән чаралар:

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында шәхсән үзем катнашырга җыенам/җыенмыйм (кирәгенең астына сызарга).

"__" _________ 20__ ел. _________________ ______________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)